| Республика Татарстан<br>Совет Верхне-Чершилинского<br>сельского поселения<br>Сармановского<br>муниципального района | Татарстан Республикасы<br>Сарман муниципаль<br>районының Югары Чыршылы<br>авыл җирлеге Советы |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

30.12.2025 № 13

Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән гектарларда яисә баллогектарларда күрсәтелгән җир кишәрлегенә гади ялгыз вакланма рәвешендә өлешләрнең күләмнәрен билгеләү нәтиҗәләрен раслау турында

«Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең әйләнеше турында» 24.07.2002 ел, №101-ФЗ Федераль законны үтәү йөзеннән, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законга таянып, РФ Хөкүмәтенең 16.09.2020 ел, № 1475 «авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең күләмнәрен билгеләү Кагыйдәләрен раслау турында» Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Югары Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы белән, күчемсез мөлкәт объектына төп характеристикалар һәм теркәлгән хокуклар турында күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан 23.12.2025 елгы өземтә нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Югары Чыршылы авыл җирлеге» Советы хәл итә:

1. Татарстан Республикасы, Сарман муниципаль районы, адресы буенча урнашкан 16:36:000000:160 номерлы, 1879331 кв. м. мәйданлы җир кишәрлегенә гомуми өлешле милек хокукында гади дөрес вакланма рәвешендә гектарларда белдерелгән авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән өлешләр күләмнәрен билгеләү нәтиҗәләрен расларга.карарга.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

3. Әлеге карарны уставта билгеләнгән тәртиптә өч көн эчендә рәсми рәвештә халыкка чыгарырга.

4. Әлеге карар рәсми игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Югары Чыршылы авыл җирлеге совет рәисе Р.М.Гилева